Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
гражданнар Каськи аылы җыен нәтиҗәләре турындагы карары

27 ноябрь 2024 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2024 елның 25 ноябрендә18сәгать 00 минутта булгангражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаиләәгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме:торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу); торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне планлаштыру, буа ярын чистарту)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 20 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 10«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 2«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыИске Михайловкаавыл җирлегенең Каськи авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертү, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу); торак пункт территориясен төзекләндерү (территорияне планлаштыру, буа ярын чистарту)?”турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьнаяурам, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт,территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин